Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Советы

**КАРАР №LIV-8**

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 5 августы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарәсе депутатына, аның сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазифаи затына карата үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып күрсәтү алай ук мөһим (җитди) булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү Тәртибе хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар, “Муниципаль вазифаны яисә контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазифасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, муниципаль вазифаларны яисә контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазифаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру тәртибе турында” 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы, “Муниципаль вазифаларны, контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазифасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм контракт буенча муниципаль вазифаларны, җирле хакимият башлыгы вазифаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында” 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарәсе депутатына, аның сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазифаи затына карата үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм

мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып күрсәтү алай ук мөһим (җитди) булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү Тәртибен расларга (Кушымта).

2. Карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан (халыкка игълан ителгәннән) соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты җитәкчесе Р.Р.Җамалиевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2020 елның 5августындагы
LIV-8 номерлы карарына
кушымта

## Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә депутатына, аның сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазифаи затына карата үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып күрсәтү алай ук мөһим (җитди) булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә депутатына, аның сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазифаи затына (алга таба – муниципаль вазифаны биләүче зат) карата үзенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре (алга таба – керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар) турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүмат биргән өчен, әгәр дә бу мәгълүматларны бозып күрсәтү алай ук мөһим (җитди) булмаса, җаваплылык чаралары (алга таба – җаваплылык чаралары) куллану турында карар кабул итү процедурасын регламентлаштыра (тәртипкә сала).

2. “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 маддәсендәге $7^{3-1}$ өлеше нигезендә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес яки тулы булмаган мәгълүматлар биргән муниципаль вазифаларны биләүче затларга түбәндәге җаваплылык чаралары кулланыла:

1) кисәтү;

2) депутатны, муниципаль берәмлек җирле үзидарәсенең сайланулы органы әгъзасын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органындагы, җирле үзидарәнең сайланулы органындагы вазифасыннан аның вәкаләтләре чоры тәмамланганчы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, муниципаль берәмлекнең сайланулы органында вазифа биләү хокукыннан мәхрүм итеп азат итү;

3) даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкару хокукыннан мәхрүм итү;

4) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы вәкиллекле органында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле

үзидарәсенең сайланулы органында аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы үз вазифасын биләүне тыю;

5) вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.

3. Муниципаль вазифаларны биләүче затларга карата әлеге Тәртипнең 2 пунктында санап үтелгән җаваплылыкның берәр чарасын куллану мәсьәләсе Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы (алга таба – Совет) тарафыннан карала.

Әлеге мәсьәләне карау өчен нигез булып “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 маддәсендәге 73 өлешендә күздә тотылган Татарстан Республикасы Президентының муниципаль вазифаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасы (белдерүе, мөрәҗәгате) тора.

4. Җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президенты гаризасы (белдерүе, мөрәҗәгате) Советка килеп ирешкәннән соң өч айдан да соңга калмыйча карала.

5. Совет муниципаль вазифаны биләүче затка аңа карата җаваплылык чараларын куллану мәсьәләсен карау турында күрсәтелгән мәсьәләне карау датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча язма рәвештә хәбәрнамә ирештерә.

Совет утырышы урыны һәм вакыты турында хәбәр ителгән муниципаль вазифаны биләүче затның килмәве Татарстан Республикасы Президентының җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасын (белдерүен, мөрәҗәгатен) карауга комачауламый.

6. Муниципаль вазифаны биләүче затка җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президенты гаризасы (белдерүе, мөрәҗәгате) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 28 мартындагы XXXVI-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә Совет утырышында карала (алга таба – Регламент).

Күрсәтелгән мәсьәләне караганда муниципаль вазифаны биләүче затка тапшырылган мәгълүматлар буенча аңлатмалар бирү мөмкинлеге бирелергә тиеш.

Муниципаль вазифаны биләүче затка җаваплылык чараларының берсен куллану мәсьәләсе каралганда депутатлар тарафыннан мәнфәгатьләр низагын булдырмау һәм җайга салу буенча таләпләр үтәлергә тиеш. Совет утырышында рәислек итүче депутатларга мәнфәгатьләр низагының булуы яисә аның барлыкка килү мөмкинлеге турында хәбәр итәргә тәкъдим итәргә тиеш.

Мәнфәгатьләр низагын булдырмау яки җайга салу максатларында мәнфәгатьләр низагы ягы булган депутат карар кабул итүдән рәислек итүче тарафыннан читләштерелә.

7. Татарстан Республикасы Президенты гаризасын (белдерүен, мөрәҗәгатен) карау нәтиҗәләре буенча муниципаль вазифаны биләүче затка карата җаваплылык

чараларын куллану яисә җаваплылык чарасын куллануда баш тарту турында карар кабул ителә.

Әлеге карар Регламентта билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

Татарстан Республикасы Президенты гаризасы (белдерүе, мөрәҗәгате) бирелгән (кергән) депутат тавыш бирүдә катнашмый.

8. Җаваплылык чараларын куллану турындагы карар, кылынган коррупциячел хокук бозуның характерын, аның авырлыгын, нинди шартларда (хәлләрдә) кылынуын исәпкә алып, гаделлек, туры килү (ярашлылык), пропорциональлек һәм котылгысызлык принциплары нигезендә, шулай ук муниципаль вазифаны биләүче затның үз вазифаи бурычларын (вәкаләтләрен) үтәүнең моңа кадәрге нәтиҗәләрен, коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән башка чикләүләрне, тыюларны һәм йөкләмәләрне үтәвен исәпкә алып кабул ителә.

Хисап чорында керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында төгәл булмаган яисә тулы булмаган мәгълүматлар биргән өчен бер генә җаваплылык чарасы кулланылырга мөмкин.

9. Җаваплылык чараларын куллану турындагы карарда коррупциячел хокук бозуга, муниципаль вазифаны биләүче зат тарафыннан бозылган норматив хокукый актларның нигезләмәләренә, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә карарларга шикаять белдерү хокукына күрсәтү булырга тиеш.

10. Җаваплылык чарасын куллануда баш тарту турындагы карарда мондый баш тартуны дәлилле нигезләү булырга тиеш.

11. Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын куллануда баш тарту турындагы карарның күчермәләре кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә муниципаль вазифа биләүче затка имза куйдырып тапшырыла яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аркылы җибәрелә, шулай ук Татарстан Республикасы Президентына юллана.

Җаваплылык чарасын куллану турында карарны муниципаль вазифаны биләүче затка җиткереп булмаса яки күрсәтелгән зат карарны кул куеп кабул итүдән баш тарткан очракта Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы урынбасары тарафыннан югарыда күрсәтелгән затның җаваплылык чарасын куллану турындагы карар белән танышуны кире кагуы хакында яисә андый карар турында аңа хәбәрнамә ирештерү мөмкинлеге булмау турында акт төзелә.

12. Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын куллануда баш тарту турындагы карарга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.